ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

15.02.2016 Казан ш. № 12

**Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмә раслау хакында**

“Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче затлар һәм бүтән затлар тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 22.12.2015 № 650 Россия Федерациясе Президенты Указы кабул ителү сәбәпле һәм Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә коррупциягә каршы көрәш буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне расларга.
2. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Башлык В.А. Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең
2016 елның “15”02
№ 12 боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” № 79-ФЗ Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, 2003 елның 16 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, 2006 елның 4 маендагы “Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында” № 34-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, 2010 елның 1 июлендәге “Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында” № 821 Россия Федерациясе Президенты Указы, 2010 елның 25 августындагы “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында” № ПУ-569 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә (алга таба – Инспекция) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияне (алга таба - Комиссия) төзү һәм аның эшчәнлеген формалаштыру тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына, шушы Нигезләмәгә, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, бүтән дәүләт органнары актларына таяна.

3. Комиссиянең төп бурычы булып түбәндәгеләргә ярдәм итү тора:

а) Инспекциядә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) тарафыннан чикләмәләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яки җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү, шулай ук “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән вазифалар (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр

каршылыгын җайга салу турында таләпләр) үтәлешен тәэмин итү;

б) Инспекциядә коррупцияне кисәтү буенча чаралар башкару.

4. Комиссия Инспекциядә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазифаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазифалары) биләүче дәүләт хезмәткәрләренең (аларга билгеләү һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән кала) хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлешенә бәйле мәсьәләләрне карый.

5. Инспекциядә аларга билгеләү һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлешенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия тарафыннан карала.

6. Комиссия Инспекция боерыгы белән төзелә. Аталган акт нигезендә комиссиянең саны һәм аның эшләү тәртибе раслана.

Комиссия составына Комиссия рәисе, Инспекция башлыгы тарафыннан Инспекциядә дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче Комиссия әгъзалары саныннан билгеләнә торган Комиссия рәисе урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзалары керә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия була. Комиссия рәисе булмаганда аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) Инспекция башлыгының беренче урынбасары (комиссия рәисе), Инспекциянең дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеге башлыгы, дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган вазифаи зат (комиссия сәркатибе), юридик бүлекнең, Инспекциядәге башка бүлекләрнең Инспекция башлыгы тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе вәкиле;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәтенә бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

8. Инспекция башлыгы Комиссия составына Инспекция карамагында төзелгән Иҗтимагый совет вәкилен кертү турында карар кабул итә ала.

9. Нигезләмәнең 7 пунктының “б” һәм “в” пунктчаларында һәм 8 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт

хезмәте һәм кадрлар мәсьәләсе буенча бүлекчәсе, фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, Инспекциядә төзелгән Иҗтимагый совет белән килештереп билгеләнгән тәртиптә, Инспекция башлыгының гарызнамәсе нигезендә кертеләләр. Килештерү гарызнамәне алган көннән соң 10 көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

10. Комиссиянең дәүләт органында дәүләт хезмәте вазифаларын биләмәгән әгъзаларының саны Комиссия әгъзаларының тулы саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

11. Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеген булдырмаслык итеп төзелә.

12. Комиссия утырышларында киңәшмә тавыш бирү хокукы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә торган, дәүләт органында дәүләт хезмәте вазифаларын, аңа карата Комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре били торган аналогик вазифаларны биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) Инспекциядә дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте һәм комиссия тарафыннан каралучы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алырга мөмкин булган белгечләр; башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары вазифаи затлары; кызыксынган оешмаларның вәкилләре; аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле, – аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең яки комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенеч язуы нигезендә комиссия утырышы көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, комиссия рәисе тарафыннан һәр конкрет очракта аерым кабул ителә торган карар буенча.

13. Комиссия утырышы анда комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашканда тулы хокуклы була.

Дәүләт органында дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү рөхсәт ителми.

14. Комиссия әгъзасының комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне карап тикшергәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчыга кадәр бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта комиссиянең тиешле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерүдә катнашмый.

15. Комиссия утырышын үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәткәре тапшыра торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлүенә карата үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекция башлыгы тарафыннан түбәндәгеләрне таныклый торган тикшерү материаллары тапшырылу:

дәүләт хезмәткәре тарафыннан 2009 елның 30 декабрендәге № ПУ-702 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылу турында нигезләмәдә каралган белешмәләрне ышанычсыз яки тулы булмаган күләмдә тапшырылу хакында;

дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлмәве хакында;

б) дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлегенә яисә коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазифаи затка Инспекциянең норматив-хокукый актында билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр кергәндә:

Инспекциядә Татарстан Республикасы Президенты раслаган вазифалар исемлегенә кертелүче дәүләт гражданлык хезмәте вазифасын биләгән гражданның, дәүләт хезмәтеннән куылу көненнән алып ике ел узганчыга кадәр, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым вазифалары аның вазифаи (хезмәт) бурычларына караган булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа биләүгә яисә гражданлык-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада эшләр башкаруга рөхсәт бирү турындагы мөрәҗәгате;

дәүләт хезмәткәренең нигезле сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге яки мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең, территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, акчалата акча чаралары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган чит ил дәүләтенең вәкаләтле органнары тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле сәбәпле, яки аның ихтыярына яки аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар булу сәбәпле, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны

тыю турында” № 79-ФЗ Федераль закон (алга таба – “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” Федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында белдерүнамәсе.

в) Инспекция башлыгының яисә комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен яисә Инспекциядә коррупцияне кисәтү буенча чаралар башкарылуны тәэмин итүгә кагыла торган йогынты акты;

г) Инспекция башлыгы тарафыннан дәүләт хезмәткәренең “Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында” Федераль законның 3 статьясының 1 өлешендә каралган мәгълүматларны ышанычсыз яки тулы булмаган күләмдә тапшыруы турында таныклый торган материаллар тапшырылу;

д) 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясының 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмадан Инспекциягә килгән, дәүләт органында дәүләт гражданлык вазифасын биләгән граждан белән, әгәр дә дәүләт органында вазифа биләү вакытында дәүләт идарәсенең аерым вазифалары аның тарафыннан башкарыла торган вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, күрсәтелгән гражданга комиссия тарафыннан элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керүгә ризалык бирелмәсә яки мондый гражданга аның тарафыннан коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа биләүгә яисә аның тарафыннан гражданлык-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада эшләр башкаруга рөхсәт бирү турындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан каралмаган булса, эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамә төзү турында белдерүнамә.

16. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасы бозылу очраклары буенча тикшерүләр үткәрми.

16.1. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәте вазифасын биләгән граждан тарафыннан дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте бүлегенә яисә коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган вазифаи затка тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү

урыны буенча адресы, дәүләт хезмәтеннән куылган көннән башлап соңгы ике ел дәвамында биләгән вазифалары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманың аталышы, урнашкан урыны, аның эшчәнлек итү характеры, гражданның аның тарафыннан дәүләт хезмәте вазифасын биләгән чорда башкарылган вазифаи (хезмәт) бурычлары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе буенча вазифалар, шартнамә төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), күзалланган гамәлдәге вакыты, шартнамә буенча эшләр (хезмәтләр) башкаруга (күрсәтүгә) түләү суммасы.

Дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек яки коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган вазифаи зат тарафыннан мөрәҗәгать карап тикшерелә, аның нәтиҗәсендә, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

16.2. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать үзенең дәүләт хезмәтеннән куылуын планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелергә мөмкин һәм комиссия тарафыннан Нигезләмә нигезендә карап тикшерелергә тиеш.

16.3. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән белдерүнамә дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек яки коррупция һәм башка төрле хокук бозулар эше өчен җаваплы булган вазифаи зат тарафыннан карап тикшерелә, соңгысы Инспекциядә дәүләт хезмәте вазифасын биләгән граждан тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы таләпләрнең үтәлеше турында дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

16.4. Шушы Нигезләмәнең 15 пунктының “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән белдерүнамә дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек яисә коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган вазифаи зат тарафыннан карап тикшерелә, соңгысы белдерүнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.

16.5. Шушы Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки шушы Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында һәм “д” пунктчасында күрсәтелгән белдерүнамәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмәне әзерләгәндә дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек яисә коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган вазифаи зат мөрәҗәгатьне яки белдерүнамәне җиткергән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмәләр үткәрергә, аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы, ә Инспекция башлыгы яки Инспекция башлыгының беренче урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрә ала. Мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерүнамә килгән көннән башлап

җиде эш көне дәвамында комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерүнамә килгән көннән башлап 45 көн дәвамында тапшырыла. Аталган вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыграк түгел.

17. Комиссия рәисе, аңа Инспекциянең норматив-хокукый актында каралган тәртиптә комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат килеп ирешкәндә:

а) 10 көнлек срокта комиссиянең утырыш көнен билгели. Шул ук вакытта комиссия утырышының көне, әлеге Нигезләмәнең 17.1 һәм 17.2 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып 20 көннән дә соңгарак калып билгеләнә алмый;

б) аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, комиссия әгъзаларын һәм комиссия утырышында катнашучы башка затларны дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеккә яки коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган вазифаи затка килеп ирешкән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) Комиссия утырышына Нигезләмәнең 12 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенеч язуларын карап тикшерә, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карап тикшерү (карап тикшерүдән баш тарту) турында карарлар кабул итә.

17.1. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаны карап тикшерү буенча комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән вакыт узган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

17.2. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән белдерүнамә, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карап тикшерелә.

18. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәре яки Инспекциядә дәүләт хезмәте вазифасын биләгән граждан катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхси катнашырга ниятләве хакында дәүләт хезмәткәре яисә граждан шушы Нигезләмәнең 15 пунктының “б” пунктчасына туры китереп тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә күрсәтә.

18.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт хезмәткәре катнашыннан башка үткәрелә ала:

а) шушы Нигезләмәнең 15 пунктының “б” пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә дәүләт хезмәткәренең комиссия

утырышында катнашырга ниятләве турында күрсәтелмәсә;

б) комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм аның вакыты һәм үткәрелү урыны турында тиешенчә хәбәр алган дәүләт хезмәткәре комиссия утырышына килмәсә.

19. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең (аның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка кертелгән мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карап тикшерелә.

20. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

21. Нигезләмәнең 15 пунктындагы "а" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан 2009 елның 30 декабрендәге № ПУ-702 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең ышанычлы һәм тулы булуын билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Нигезләмә нигезендә тапшырылган, әлеге пунктның "а" пунктчасында аталган белешмәләрнең ышанычсыз һәм (яки) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта комиссия Инспекция башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

22. Нигезләмәнең 14 пунктындагы "а" пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлүен билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәвен билгеләргә. Бу очракта комиссия Инспекция башлыгына дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлмәвенә юл куелмаска тиешлеген күрсәтергә яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

23. Нигезләмәнең 15 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым вазифалар аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел

яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирергә;

б) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым вазифалар аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирмәскә һәм бу рөхсәт бирмәүне нигезләргә.

24. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмауның сәбәбе объектив һәм хөрмәткә лаек дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмауның сәбәбе нигезле түгел дип танырга. Бу очракта комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмауның сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан качу ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта комиссия Инспекция башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

24.1. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “г” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан “Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында” Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларның ышанычлы һәм тулы булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан “Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында” Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларның ышанычсыз һәм тулы булмавын танырга. Бу очракта комиссия Инспекция башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тоту барышында алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки), аларның компетенцияләре кысаларында, башка дәүләт органнарына җибәрергә киңәш итә.

24.2. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының дүртенче

абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкин булмаган шартларның объектив һәм хөрмәткә лаек булуын танырга;

б) “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкин булмаган шартларның объектив булмавын һәм нигезсез булуын танырга. Бу очракта комиссия Инспекция башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

24.3. Шушы Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының бишенече абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршлыгы булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре вазифаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлыкның мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм Инспекция башлыгына мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки аның барлыкка килүенә юл куймау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта комиссия Инспекция башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата аерым бер җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

25. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “а”, “б”, “г” һәм “д” пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булган очракта, комиссия Нигезләмәнең 21-24, 24.1-24.3 пунктларында каралганнардан аермалы карарлар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итү нигезләре һәм сәбәпләре комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

25.1. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия Инспекциядә дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аның тарафыннан, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым вазифалар аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылуга рөхсәт бирергә;

б) аның тарафыннан коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа биләү яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылу (хезмәтләр күрсәтелү) 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы таләпләрне боза дип билгеләргә. Бу очракта комиссия Инспекция башлыгына күрсәтелгән шартлар турында прокуратура органнарына һәм хәбәр итүче оешмага җиткерү турында киңәш итә.

26. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “в” пунктчасында каралган мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия тиешле карар кабул итә.

27. Комиссия карарларын үтәү өчен билгеләнгән тәртиптә Инспекция башлыгына карап тикшерү өчен тапшырыла торган Инспекциянең норматив-хокукый актлары, Инспекция башлыгының карарлары яки йөкләмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин.

28. Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча комиссия карарлары яшерен тавыш биреп (әгәр комиссия башка төрле карар кабул итмәсә), комиссия утырышында катнашучы әгъзалары тавышларының гади күпчелеге нигезендә кабул ителә.

29. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларны комиссиянең утырышында катнашкан әгъзалары имзалый. Комиссия карарлары, Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карардан кала, Инспекция башлыгы өчен киңәш бирү характерына ия. Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар зарури характерга ия.

30. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышының көне, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазифасын күрсәтеп, комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең тәгъбирләнеше;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелгән дәгъвалар, аларны нигезли торган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылына карата аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) комиссия утырышын үткәрү нигезен эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның дәүләт органына килү көне;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итү турында нигезләмә.

31. Комиссиянең карары белән риза булмаган әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә беркетелергә һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышырга тиеш.

32. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш көненнән соң 7 көнлек срокта Инспекция башлыгына, тулысынча яки аннан өземтә рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук комиссия карары буенча – башка кызыксынган затларга җибәрелә.

33. Инспекция башлыгы комиссия утырышы беркетмәсен карап тикшерергә бурычлы һәм үзенә бирелгән вәкаләт кысаларында дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында карар кабул иткәндә һәм коррупциягә каршы көрәш оештыруның башка төрле мәсьәләләре буенча андагы киңәшләрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия киңәшләрен карап тикшерү һәм кабул ителгән карар турында Инспекция башлыгы язмача рәвештә аңа комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән соң бер айлык срокта комиссиягә хәбәр итә. Инспекция башлыгы карары комиссиянең якын киләчәктәге утырышында игълан ителә һәм фикер алышуларсыз гына игътибарга алына.

34. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаеп билгеләре ачыкланган очракта, бу хактагы мәгълүмат, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында мәсьәләне хәл итү өчен, Инспекция башлыгына тапшырыла.

35. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләрен яки җинаять составын үз эченә алучы гамәлләрне кылуы (гамәл кылмавы) ачыкланган очракта, комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылыну (гамәл кылынмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый очракны раслый торган документларны 3 көнлек срокта, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук кулланучы органнарга тапшырырга бурычлы.

36. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан алынган өземтә аңа карата комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында мәсьәлә карап тикшерелгән дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

36.1. Комиссия карарыннан алынган, комиссия сәркатибенең имзасы һәм Инспекция мөһере белән таныкланган өземтә аңа карата Нигезләмәнең 15 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә карап тикшерелгән, Инспекциядә дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданга имзалатып тапшырыла яки аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча, комиссиянең тиешле утырышы үткәрелгән көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, белдерүнамә белән заказлы хат итеп җибәрелә.

37. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документаль яктан

тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырыш көне, вакыты һәм үткәрү урыны турында хәбәр итү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышу өчен тапшырыла торган материаллар белән таныштыру Инспекциянең дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеге яки коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы булган вазифаи зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.